وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

# Дин вә Мәгыйшәт

№5 (102). 16 сентябрь 2011 / 18-шәүвәл-1432

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



19 сентябрьдә Шамил Галәветдинов Азнакайга киләчәк ▷2◁



Мөслимә һәм ислам дине ▷3◁



Әниләр хакы ▷4◁

## Өммәтебезне ныгыту юлларын эзләргә кирәк

**Бүгенге көндә иң катлаулы чорларның берсен кичерәбез. Реклама гасыры... Яшәешебез теләсә нинди юллар белән бары үзеңә генә файда эзләүдән гыйбарәт. Күп нәрсәләр материаль төшенчәләр белән аңлатыла.**



Рухи дөнья, вөждан, намус кебек гыйбарәләрнең нәрсә икәнлеген дә онытып барабыз. Югыйсә, тарих безгә гыйбрәт алырлык сабакларны җитәрлек бирде бит инде. Бүгенге хаталар алдагы буыннарда күзәтелмәгәндер дисезме? Дини спекуляция аркасында Аллаһы Тәгалә бер төркем кешеләрне генә түгел, корычтай нык булган цивилизацияләрне дә юкка чыгарган.

Соңгы вакытта җәмәгатьчелектә Мәскәү Җәмигъ мәчете турында сүз куерды, әйтерсең лә, мөселманнарның моннан башка проблемалары юк. Бу очракта яңа мәчет төзергә теләүчеләрне дә, тарихи мәчетне саклап калуны хуплаучыларны да аңлап була. Шулай да ниндидер карар чыгармыйк, барысын да вакыт күрсәтер. Аллаһы Тәгалә боерганны үзгәртеп булмый. Моннан ниндидер тамаша ясап, кеше көлдерү кирәк түгел. Сүз куертып, гаепләләрне эзләп, мөселман өммәтендә янә ызгыш чыгарудан файда юк безгә. Барысын да Аллаһы Тәгалә кулына тапшырыйк һәм булган һәр нәрсәнең яхшы якларын гына күрергә өйрәник. Аллаһы Тәгалә Коръәндә: "Сез игелек дип уйлаганыгыз начарлык булыр. Бәлки, сез нәрсәнедер күралмассыз, ә ул яхшылык булыр. Аллаһ кына барысын да белә", – дип әйткән.

Кызганычка каршы, гаделсезлекне тамырыннан юкка чыгару мөмкин түгел. Бары Аллаһы Тәгалә генә безнең бөтенебез белән гадел. Шуңа күрә дә Аңа гына таянырга, юлдан язганнарга булышуын, иманыбыз һәм динебезне ныгытуын сорарга кирәк.

Без, мөселманнар, халыкның рухи ягын кайгыртабыз. Үзебез фани дөнья – сыеныр урын гына дибез, шул ук вакытта бар көчебез белән шушы дөньяга береккәнбез. Бер-берсен рәнҗетүдән дә, кеше үтерү, урлаудан да курыкмый адәм баласы. Шайтан коткысына бирелеп күпме яшәргә була? Җитәр, туктарга вакыт! Шайтан арабызда бары тик гауга-талашлар һәм дошманлык кына тудыра.

Шайтан вак кына мәсьәләләрне дә зур итеп күрсәтә, мөһим, кирәкле эшләрне игътибарсыз калдырырга котырта. Мөселман өммәтен ныгыту юлларын эзләргә кирәк, ә без исә һаман да тарткалашу өчен сәбәпләр эзләвебезне дәвам итәбез.

*Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ*

## Җәйге мөселман лагерьлары буенча йомгак ясалды

***Быел республикабызның кырык биш районының кырык дүртендә мөселман яшүсмерләре өчен көндезге һәм җәйге стационар лагерьлар үткәрелде.***

Күпчелек лагерьлар мәчетләр каршында оештырылды.

Лагерьларга биш меңнән артык кеше – алтыдан алып унҗиде яшькә кадәр булган малайлар һәм кызлар йөрде.

Алар ислам дине буенча белем туплап кына калмады, бабаларыбызның рухи мирасын өйрәнә алды, шулай ук мөселманнар мохитендә актив ял итте.

2007-2009 елларда үткәрелгән мөселман лагерьлары статистикасына күз салсак, ул вакытта лагерьларга йөрүчеләр саны дүрт мең тирәсе булган, ә 2010-2011 уку елында исә мондый төрдәге лагерьларга баручылар мең кешегә арткан.

Җәйге лагерьлар булдыруда активлык күрсәткән, ял итәргә килүчеләре күп булган, чагыштырмача татар җирлекле төбәкләргә Арча (47 мең татары булган районның алты йөздән артык баласы лагерьларга йөрде), Чирмешән (биредә 11 мең татар яши, шуның йөз иллеләбе ял итте), Ютазы (13 мең татарның йөз алтмышлап баласы лагерьларга барды), Балык бистәсе (21 мең татарның ике йөздән артык баласы җәйге ялын лагерьда уздырды) районнары керә.

Нәтиҗәләргә күз салсак, республикабыз шәһәрләре районнарга караганда начаррак күрсәткеч бирде. Мисал өчен, меңьеллык Алабуга каласында 34 мең татарның егермеләп баласы гына мөселман лагерьларында күреште. (Ә башкалабызда исә (Казанда 576 мең татар яши) өч йөздән артык бала мөселман лагерьларында булды). Чаллы шәһәрендә яшәүче 233 мең татарның йөз алтмышка якын баласы, Яшел Үзәндә 68 мең татардан иллегә якыны мөселман лагерьларында ял иткән. (Бу саннар мөхтәсибәт күләмендә бирелә).

Шулай итеп, республикабыз балалары һәм яшүсмерләренең җәйге ялына йомгак ясаганда, Татарстан районнарындагы татар халкы саны җәйге мөселман лагерьларында ял иткән балалар санына бәйле рәвештә каралды.

*ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең уку-укыту бүлеге*

## КОРЪӘНИ-КӘРИМНЕҢ МЕТАПРОГРАММАЛЫ ПРОФИЛЕ



**Психология фәне "кешенең метапрограммалары" төшенчәсен ачты. Метапрограммалар − ул безнең игътибар үзәгенә эләккәнче үк мәгълүматны аралаучы аңның фильтрлары. Кеше үзенең метапрограммалары эшчәнлеген күзәтә алмый, алар кешегә эчке яктан тәэсир итә һәм билгеле бер мәгънәдә кеше аларга тулысынча бәйле. Кеше белән билгеле бер конкрет ситуациядә җитәкчелек итүче метапрограммалар җыелмасы аның метапрограммалы профилен тәшкил итә. Бу аның эчке дөньясының структурасын тасвирлаган паспорт сыман.**

Соңрак билгеле булганча, метапрограммалы профильне кешенең үзенә генә түгел, аның психик реальлегенең аерым элементларына, мәсәлән, эмоцияләргә төзү мөмкин. Бер эмоциянең төрле төсмерләре арасындагы аермалары (мәсәлән: ачу, ярсу, канәгатьсезлек һ.б.) нәкъ менә аларның метапрограммалы профильләрендәге кечкенә генә аерма белән билгеләнә. Метапрограммалы профильдә конкрет эмоциянең бер генә метапрограммасын алыштырып карау да, аның яңа төсмерен алуга китерә.

Әлеге ачыш психотерапевтлар эшенә зур ярдәм булып тора. Клиентның эмоциясендә бер метапрограмманы икенчесенә алыштыру аны бер халәттән икенчесенә күчерү мөмкинлеген бирә: башта ярсуны ачуга, ачуны – канәгатьсезлеккә, ә аннары, метапрограмманы ресурслырак халәткә күчерүне дәвам итеп "борырга" була, мәсәлән, тынычлыкка һәм шатлыкка. Хәзерге вакытта тикшерүчеләр барлык төр эмоцияләрнең дә метапрограммалы профильләрен төзегәндә аларның кечкенә төсмерләре һәм нюансларын исәпкә алып, кешенең эмоциональ дөньясы картасын ясыйлар һәм бер эмоциядән башкасына маршрутларны җайлау өстендә эшлиләр.



Шул ук вакытта метапрограммаларны төрле текстларда да табалар. Һәртөрле сөйләмнең дә (шул исәптән, текст та) үзенең метапрограммалы профиленә ия булуы билгеле булды. Бер яктан, аны белеп, без текстның эмоциональ фонын ачыклый алабыз. Икенче яктан, бу безгә текстның эчтәлеге артында торган структураны күрергә мөмкинлек бирә. Менә монда иң кызыгы башлана да инде.

Без төрле дини текстларның да метапрограммалы профильләрен төзи алабыз, бу аларны үзара эчтәлекләре дәрәҗәсендә генә түгел, ә структуралары дәрәҗәсендә дә тиңләштерү мөмкинлеген бирә. Миңа калса, бу ислам дине хәзинәсен өйрәнүгә яңа методологик ачкыч бирергә мөмкин. Безнең кулда Коръәни-Кәримнең метапрограммалы профиле бар дип күз алдына китерегез.

Бу – безнең эталонлы белем структурасына керү мөмкинлеге бар дигән сүз. Хәзер төрле дини агымнар һәм группалар (хәнәфиләр, шәфигыйләр, исмәгыйләр, ваһһабчылар, әхмәдиләр һ.б.) текстларының метапрограммалы профильләрен төзеп, без аларны ислам эталоны структурасы дәрәҗәсенә туры китереп, ягъни хак тәгълимат белән чагыштырып, өйрәнә алачакбыз.

*(Ахыры 3 биттә.)*

## ИГЪЛАН

**2011 ЕЛНЫҢ 27 СЕНТЯБРЕНДӘ 10 СӘГАТЬТӘ** ***Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте мәчет каршында эшләп килүче курсларның укытучылары белән республика киңәшмәсе үткәрәчәк. Семинар Газовая урамы, 19 нчы йорт адресы буенча урнашкан РИУның актлар залында узачак. Республикабыздагы мәчет каршындагы курсларда тугыз йөз иллеләп мөгаллим эшли, шуларның өч йөзе бу чарага делегат буларак чакырылган.***

# Дини белем бирүче мөгаллимнәр киңәшмәсе уздырылачак

***Бу хакта Арча районында үткәрелгән имам-хатыйблар җыелышында хәбәр ителде. Анда җитмештән артык мәхәлләдән дин әһелләре, шул исәптән мәхәллә каршында эшләп килүче башлангыч дини белем бирүче абыстайлар катнашты.***

Җыелышка Тау ягы, Кама аръягы һәм Төньяк казыяткә караган 14 районның имам-мөхтәсибе килгән иде.

Җыелышта ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең гомуми бүлек мөдире Ильяс хәзрәт Җиһаншин, "Зәкят" фонды җитәкчесе Рөстәм хәзрәт Ясәвиев, шулай ук Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев чыгыш ясады.

Җәлил хәзрәт җыелган халык алдында вәгазь сөйләде. Имам-хатыйбларга сентябрь ахырында мәхәлләләр каршындагы башлангыч дини белем бирүче мөгаллимнәрнең киңәшмәсе үтәчәген хәбәр итте.

Ильяс Җиһаншин мөфти Илдус хәзрәт Фәиз исеменнән Арча районы имам-мөхтәсибе Раил хәзрәт Гыйләҗевне 35 яшьлек юбилее белән котлап, истәлекле бүләкләр тапшырды.

*intertat.ru сайтыннан алынды*

# Татар бистәсе тагын бер музейга артачак

***Башкалабыздагы Мәрҗани урамында урнашкан 8 нче йортта Иске татар бистәсе музее оештырылачак.***

12 сентябрь көнне бу хакта Казан шәһәре башкарма комитеты җитәкчесенең 2013 елда Универсиада уздыруга әзерлек мәсьәләләре өчен җаваплы урынбасары Руслан Шакиров хәбәр итте. Аның сүзләренә караганда, иң элек Мәрҗани урамындагы 8 нче йорт (ул сәүдәгәр Сабитовлар биләмәсе булган) реставрацияләнәчәк.

– Бу – муниципалитетның үз проекты. Без аны финанслауны шәһәрнең киләсе ел бюджетына салырга уйлыйбыз, – дип хәбәр итте Руслан Шакиров tatar-inform.ru сайты хәбәрчесенә. Әлегә финанслау күләме әйтелми. "Бүгенге көндә анда кешеләр яши. Әле аларны күчерергә кирәк", – дип белдерде Руслан Роберт улы.

**Римма ГАТИНА.**



# 19 сентябрьдә Шамил ГАЛӘВЕТДИНОВ Азнакайга киләчәк

***Казандагы "Ак Барс" яшьләр үзәгендә Мәскәүнең "Мемориаль" мәчете имам-хатыйбы, Россиянең Европа өлеше мөселманнары Диния нәзарәтенең фәнни-дини шура җитәкчесе, егермедән артык дини китап авторы Шамил Галәветдинов белән очрашу 1-2 октябрь көннәрендә уздырылачак.***

Танылган дин әһеле Азнакай шәһәре мәдәният йортында 19 сентябрьдә чыгыш ясар, дип көтелә. Бу хакта Шамил хәзрәтнең umma.ru сайты хәбәр итә.

Очрашу алдыннан "Дин вә мәгыйшәт" газетасы редакциясе Азнакай районы имам-мөхтәсибе Әмирҗан хәзрәт Якупов белән элемтәгә керде. Менә ул безгә ниләр сөйләде:

- Ш.Галәветдинов 17-18 сентябрь көннәрендә Башкортстан Республикасының Октябрьский шәһәрендә чыгыш ясаячак. Без аны унтугызы көнне көндезге өчтә алып кайтачакбыз. Шамил хәзрәт белән очрашу ясарга килешү авыр булмады. Аның хәләл җефете безнең районныкы, ул моңа кадәр дә Азнакайга кайткалый иде. Ә бу юлы аның туганнары белән алдан сөйләшеп, мәдәният йортында икенде белән ахшам арасында очрашу уздырырга булдык, журналистларны да чакырдык, – дип сөйләде район мөхтәсибе.

Азнакайлыларга дин әһеле "Чему учит Ислам?" дип аталган китабы һәм динебезнең бүгенге тормышыбыздагы роле турында сөйләячәк. Хәзрәтнең "Нәрсә ул иман юлы? Ул безгә нәрсә бирә?" кебек сорауларга җавабы мөселман булмаганнарга да кызыклы булыр, Инша Аллаһ. Чара 17.30 сәгатьтә башланыр, дип көтелә. Керү ирекле.

1 октябрьдә Татарстан башкаласына дин белгече үзенең "Семья и Ислам" һәм "Он и она. Полная версия" китапларын тәкъдим итү нияте белән килә. Аның чыгышы да гаилә темасына багышланачак, "Гаиләдә гармония. Нигә аерылышулар була?" дип исемләнәчәк.

Казандагы очрашуның ике көнендә дә "Перевод Священного Корана. Смыслы" дип аталган китабының III томы тәкъдим ителәчәк. Шулай ук "Тормышны шатлыкка күмү" дигән темага сөйләшү каралган. Ике көнне дә ярты сәгать чыгыш ясаганнан соң хәзрәт тыңлаучыларның сорауларына җавап бирәчәк. Очрашулар 15.00 сәгатьтә башланачак.

**Нияз САБИРҖАНОВ.**



# Нурлат остазларының квалификациясен күтәрү курслары башланды


***14 сентябрь көнне Нурлат шәһәрендә мәчет каршында дини белем бирүче укытучыларның квалификацияләрен күтәрү курслары башланып китте. Курслар бер ай дәвам итәчәк.***

Әлеге курсларның ачылыш тантанасында ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисенең беренче урынбасары Габдулла хәзрәт Әдһәмов, Нурлат районы һәм шәһәре имам-мөхтәсибе Айрат хәзрәт Әюпов, Россия ислам университеты мөгаллимнәре һәм Нурлат районы мәчетләре каршында дини белем бирүче утызлап остаз катнашты.

Шушы булып үткән вакыйга турында тулырак мәгълүмат алу өчен без Нурлат имам-мөхтәсибе белән телефон аша элемтәгә кердек:

- Нурлат шәһәре һәм районы мәчетләрендә белем бирүче остазларыбызны бер айлык курсларга җыйдык. Алар Нурлаттагы Шикәр заводы бистәсенең мәхәллә мәчетендә укыячаклар. Курсларны оештыру һәм үткәрү өчен үзенең матди ярдәмен чыгышы белән районыбыздан булган, хәзерге вакытта Казанда шикәр заводлары берләшмәсенең директор урынбасары булып эшләүче Илнур Илдус улы Вәлиев кертте, - дип билгеләп узды Айрат Әюпов. - Укулар бер ай дәвамында иртәдән кичкә кадәр барачак, курсны үтүчеләр 14 октябрь көнне аттестация имтиханын тапшырачак.

**Нияз САБИРҖАНОВ.**



# Татарстан ислам журналистлары әзерли башлады

***Россия ислам университетының (РИУ) теология факультетында журналистика юнәлеше ачылды. Студентлар төп белгечлекләреннән тыш, дини-теологик белем дә алачак.***

Димәк, быелдан үзләренең тормышларын журналистикага багышларга ниятләгәннәр өчен РИУ ишекләре дә ачык.

Беренче тупланган төркем җиде кешедән тора. Алар арасында яңа гына мәктәпне тәмамлаучылар белән беррәттән бүгенге көндә массакүләм мәгълүмат чараларында каләм тибрәтүчеләр дә бар. Биредә әлегә көндезге уку гына каралган. Киләчәктә исә читтән торып уку бүлеге дә барлыкка килер, дип көтелә.

Университетның уку-укыту эшләре буенча проректоры Марат Гыйльманов islam-portal.ru сайтына хәбәр иткәнчә, әлеге "факультет"ның төп үзенчәлеге булып, булачак журналистларның үз белгечлекләреннән тыш, яхшы теологик белем, ислам дине буенча өстәмә мәгълүмат алуларын билгеләп узарга мөмкин. Проректор сүзләренә караганда, факультет ислам дине турында язучы һәм дини канунннарны, тарих, мәдәният нигезләрен яхшы белүче журналистлар әзерләячәк.

Шунысын да искәртеп узыйк: республикабызда моңа чаклы мондый күпкырлы белгечлек алырга мөмкин булган башка җир юк иде.

***Гөлназ БӘДРЕТДИН.***
*(КФУ студенты Гүзәл Шәмсиева тәрҗемәсе)*

# Казанда татар телен түләүсез өйрәнеп булачак


***Тиздән Казанда татар телен өйрәнү буенча түләүсез курслар башланып китәчәк. Анда татар телен, Татарстан һәм татар халкы тарихын, шулай ук, ислам дине нигезләрен тирәнтенрәк өйрәнергә теләгән һәркем чакырыла.***

Дәресләргә йөрүчеләр гарәп телендә язылган Коръәнне тәҗвид кагыйдәләре нигезендә укырга да өйрәнәчәк.

Чараны Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты белән Россия ислам университеты оештыра.

Курслар февраль аеннан эшли башлар, дип көтелә. Ул өч айга исәпләнелгән. Дәресләр кичке алтыда сишәмбе, чәршәмбе, шимбә көннәрендә Россия ислам университетында (Газовая ур., 19 нчы йорт) үткәреләчәк. Курслар буенча оештыру җыелышы исә РИУ бинасында 1 октябрь көнне кичке сәгать алтыда булачак. Белешмәләр өчен телефон: 89503200935.

Бөтендөнья татар конгрессының матбугат хезмәте хәбәр иткәнчә, курсларга теләгән һәр кеше языла ала, программага фильмнар карау, чәй эчүләр кертелгән. Уку түләүсез.



# Бохара шәһәре татар яшьләрен җыя



***Үзбәкстан Республикасы - күпмилләтле ил. Монда йөз утыздан артык милләт вәкиле яши. Татарлар саны исә 200 меңнән дә артып китә.***

Быел ил үзенең бәйсез булуының 20 еллыгын билгеләп үтте. Шуңа бәйле рәвештә, 6-8 октябрь көннәрендә Үзбәкстанның борынгы Бохара шәһәренә экскурсия оештыру планлаштырылган.

Чара Бохараның татар мәдәни үзәге тарафыннан оештырыла. Анда Үзбәкстан, Казахстан, Кыргызстан, Таҗикстан, Төрекмәнстан, Кытай, шулай ук Латвия, Эстония, Украина, Азәрбайҗан, Башкортстан, Татарстан, Мәскәү, Төмән һ.б. төбәкләрдән татар яшьләре чакырылган. Чарада Бөтендөнья татар яшьләре форумы бюросы вәкилләре һәм башка яшьләр оешмалары да катнашыр дип көтелә. Экскурсия өчен һәркем үзе түли.

Бохара шәһәреҮзбәкстанның көньяк-көнбатышында Кызылком чүлендә урнашкан. Әлеге кала Үзбәкстан республикасының иң зур шәһәрләреннән берсе, тарихи-мәдәни туристлык үзәге булып санала. Аны ачык һавадагы шәһәр-музей дип тә йөртәләр.

1993 елда Бохараның тарихи урыннары ЮНЕСКОның Бөтендөнья мирасы шәһәрләре исемлегенә кертелгән иде. 1997 елда исә халыкара дәрәҗәдә шәһәрнең 2500 еллык юбилее зурлап билгеләп үтелде.

*intertat.ru сайтыннан алынды*

# Без китәбез, сез каласыз

***Соңгы вакытта болай да берсеннән-берсе мәгънәсез тәҗрибәләргә дучар булган авылга карата тагын бер әшәкелек уйлап табылды. Ул – «реструктуризация». Бу эшнең максаты – мәктәпләр хисабына күпмедер экономия ясау, ул акчаны бүтән максатларга (мәсәлән, хоккей, футбол, баскетбол командаларына уенчылар сатып алу булырга мөмкин) тоту. Әмма турыдан-туры болай дип әйтергә ярамый бит инде. Аз комплектлы, ягъни кыскартуга дучар булган мәктәпләрне түбәнсетеп мондый сәбәпләр китерелә:***

**1) имеш, укытучылар берьюлы дүрт-биш фән укытырга мәҗбүр һәм аларның һөнәри осталыгы түбән;**

**2) балалар укуда үзара ярыша алмый, шунлыктан начар укый;**

**3) балаларда аралашу күнекмәләре тәрбияләнми.**

Бу сәбәпләрнең авыл мәктәбендә эшләп тә карамаган бәндәләр тарафыннан уйлап чыгарылганлыгы көн кебек ачык. Авыл мәктәбендә утыз елдан артык эшләгән, күпчелек вакытында мәктәп директоры йөген тарткан кеше буларак, бу сәбәпләрне бөтенләй нигезсез дип әйтә алам. Беренчедән, башлангыч сыйныф укытучыларыннан гайре барлык укытучы да югары педагогик белемле, һәрберсе үз фәнен укыта. Зур мәктәпләрдәге укытучылар кайда белем алса, алар да шунда укыган. Тиешле вакытта аттестация үтәләр, күпчелеге I-II категориягә ия. Дәресләр саны исә сыйныфтагы балалар санына бәйле түгел. Бары рәсем, җыр, хезмәт дәресләре буенча гына белгечләр булмаска мөмкин һәм бу дәресләр башка фән укытучыларына бирелә (анда да әле программа буенча укыта алырлык булса). Икенчедән, баланың ничек укуы беренче чиратта аның сәләтенә, укуга омтылышына, аннан соң гына укытучының осталыгына бәйле. Йомшак укучы, укуга сәләте түбән бала башкалардан көнләшеп кенә яхшы укый алмый. Өченчедән, аралашу мәсьәләсендә дә төрле бала бар: аз һәм күп аралашучылар. Бу сыйфат та күбрәк нәселдән бирелә. Аннан соң, аз комплектлы мәктәпләрдә дә 40-50 бала бар бит. Аралашырга өйрәнү өчен 400-500 баланың бергә укуы кирәкмени? Аны кем һәм ничек исбат иткән? Шуның белән бергә, «балалар белән индивидуаль эш» дигән нәрсә дә куела. Ягъни, балалар азрак булган саен укытучы аерым бала белән күбрәк эшли ала.

Авыл мәктәпләренә каршы кешеләр балаларны автобус белән йөртәчәкләренә ышандырмакчы. Имеш, Европада шулай. Без бит Россиядә яшибез. Башта мондый автобуслар (ә алар арзан түгел, укытучылардан кызганган хезмәт хакы бу чыгымны капламый) тәртипле йөрергә дә мөмкин. Әмма, бераздан алар ватыла башлаячак. Аларны төзек тоту, бензин һәм запчастьләр табу һәм башка мәшәкатьләрнең акрынлап ата-аналар җилкәсенә авышуы бар. Нәтиҗәдә, балалар V сыйныфтан башлап ук ерак авылга үзләре тәпили башларга мөмкин.

Аннан соң, төрле сыйныфта дәресләр бер үк вакытта бетми һәм бетә дә алмый. Дәрестән соң түгәрәк утырышлары, сыйныфтан тыш төрле эшләр оештырыла. Сәгать уникеләрдә дәресләре беткән бала, әлбәттә, кичке сәгать дүртләргә кадәр автобус көтеп утырмый, ул кайтырга чыгачак. Аның белән юлда нәрсәләр булмас?..

***Нәҗип ВАҺАПОВ,***
***тарих фәннәре кандидаты.***

---

Рөстәм НӘБИЕВ:

## "КУЛИКОВО СУГЫШЫ ТАРИХЫН ЯҢАДАН ЯЗАРГА ВАКЫТ"



***12 сентябрь көнне "Иман" нәшриятында Рөстәм Нәбиевнең "Туктамыш ханның Алтын Урданы берләштерүе һәм "Куликово сугышы" проблемалары" исемле китабын тәкъдим итү чарасы узды.***

- Татар халкы, һичшиксез, үзенең тарихын белеп, аның белән кызыксынып яшәргә тиеш, - дип белдерде чарада катнашучылар. Тарихчылар, бөек галимнәр тарихи вакыйгаларны тирәнтенрәк тикшереп, һәр көнне диярлек яңа фикер белән алмаша.

Дүшәмбе көнне булган әлеге чарада Рөстәм Нәбиев башта үзенең китабы белән таныштырып узды, килеп туган сорауларга җавап бирергә тырышты. Тиражы нибары ике йөз данә генә булса да, китап белән кызыксынучыларга шул тәкъдим итүдә үк аны сатып алу мөмкинчелеге дә бар иде.

Әлеге китап "Куликово сугышы турында хак сүз" исемле китапка аналог буларак, өстәмәләр кертеп һәм аерым фактларга тукталып, киңрәк күзәтү ясап нәшер ителгән.

Куликово сугышы булганмы соң? Кайчан һәм кайда булган ул? Туктамыш хан бөек Мамайга карата сугыш алып барганмы яисә киресенчә, ул аны Алтын Урда җирләренә алып керергә ярдәм иткәнме?

Укучылар, укытучылар уку әсбапларында ничек бирелгән, шулай укуны кулай күреп, мондый сорауларга тукталып торуны кирәк дип тапмый. Ләкин Рөстәм Нәбиев әйтүенчә, Куликово сугышы китапларда язылганча түгел, ә икенче төрле узган.

Гомумән, Куликово сугышы Куликово кырында булмаган, ә икенче җирдә булган. Вакыты да 1380 ел түгел, ә бүтән икән. Тарих фәннәре докторы Әзһәр Мөхәммәдиев әйтүенчә, Куликово сугышы булган җирдә ни бары өч очлык кына тапканнар.

- Әгәр дә бу сугыш тарих битләрендә язылганча булган икән, ул коточкыч бәрелештән соң өч очлык кына түгел, ә меңләгән сугыш коралы табылырга тиеш иде, - дип әйтте галим.

- Хәзерге вакытта андый вакыйгаларны яңадан тарих битләреннән күтәреп, вакыты, урыны турында бәхәсләр алып бару бик кирәк, - дип саный Рөстәм Нәбиев. - Без яңа тарихка аяк басучылар булырга тиеш.

Бу тәкъдим итү чарасы түгәрәк өстәл формасында планлаштырылган булса да, Рөстәм Нәбиев бу очрашуны әңгәмә формасына әйләндерде. Тарих фәннәре кандидаты, күпләгән мәкаләләре белән танылган Искәндәр Измайлов хезмәттәше Рөстәм Нәбиев белән ачыктан-ачык бәхәскә кереп, китапның эчтәлегенә карата язучыга бик күп сораулар бирде.

Тарихның чынмы-юкмы икәнен беркем дә төгәл генә әйтә алмас. Әмма "Туктамыш ханның Алтын Урданы берләштерүе һәм "Куликово сугышы" проблемалары" исемле китап тарих белән кызыксынучылар өчен яңарыш алып килер, дип ышанып калабыз.

**Гүзәл МӘХМҮТОВА,**
**azatliq.org сайтыннан алынды**

---

# Мөслимә һәм ислам дине



**Яулык ябарга карар кылгач та, төрле фикерләр ишетергә туры килде. Кемдер Мәскәүдәге хәлләрне, яулыклы кызларны террорчылар белән тиңләүләрен, яулыклы кызларга кырын карауларын төрттерсә, кемдер эш табу проблемасы, кемдер тормыштан ерагаю, читләшү булачагы белән куркытты. Алай гына да түгел, матбугатта да еш язып торалар: имеш, яулыклы кызларга җәмәгать транспортында да усал карыйлар, урамда үтеп барышлый теләсә ни әйтеп китәргә дә мөмкиннәр. Адым саен, шикләнеп, документларыңны тикшерергә мөмкиннәр, дусларың читләшәчәк, йомык тормышта калачаксың, имештер.**

Ни кызганыч, бүген безнең әти-әниләр, абый-апалар, эне-сеңелләр исламны әнә шулай күзаллый, диннән һәм мөселманнардан курка. Террор галәмәтләреннән соң исламга карата тискәре мөнәсәбәт дулкыны килү дә эзсез калмады.

Ләкин, җәмәгать, тирәнрәк уйлап карасак, гаеп үзебездә дә бар. Ислам диненең яктылыкка, белемле, актив, югары әдәпле, ачык йөзле, киң күңелле булуга чакырганын үзебез дә еш кына онытып җибәрәбез. Яулыклы кызларыбыз кара киемнәр киеп, аяк асларына карап, башларын иеп йөргән вакытта, мөселман егетләребез һәр нәрсәдә ширек, бидгать эзләп интеккәндә, янәшәдәге дусларыбызда ислам диненә карата нинди мөнәсәбәт туарга тиеш соң?

Ак яулык, алсу күлмәк киеп, ачык йөз белән атлап барган мөселман кызын күргәч, җәмәгать исламның кара киемнәргә төренеп йөрергә кушмавын, киресенчә, ачык-якты булырга дәшүен аңлар, әйләнә-тирәдәге кешеләргә ярдәмгә ашыгучы, ачык йөзле мөселман егетләрен күреп, башкалар динебез турында да яхшыны гына уйлар иде.

Хөрмәтле дин кардәшләрем! Мөселман кешесенең һәр гамәле һәм тышкы кыяфәте, сүзләре дә дәгъвәт икәнен онытмыйк. Дәгъвәтебез уңай, исламга карата позитив фикерләр уятырлык булса иде.

Матур итеп яулыгын бәйләгән, пөхтә итеп киенгән мөселман кызларын күргәч - шундый булырга телим, дип хыяллана идем. Аллага шөкер, хиҗап кигәч дусларым да кимемәде, кырын караучыларны да күрмәдем, сүгеп-ачуланып узучыларны да очратмадым. Транспортта да төбәлмиләр, урамда да бәйләнмиләр. Әгәр культуралы итеп киенсәң, үзеңне әдәпле, итәгатьле тотсаң, нигә бәйләнергә тиешләр соң әле?

Барысы да үзебездән тора: адымнарыбыз ышанычлы, күңелләребез киң, йөзләребез ачык, киемнәребез пөхтә-матур, белемебез бай, эшләребез файдалымәгънәле булсын. Шул вакытта беркем дә ислам дине ябык тормышка, караңгылыкка илтә дип әйтмәс, динебезгә каршы килгән террор галәмәтләрен кылучы гөнаһлы бәндәләр белән безнең арада охшашлык тапмас, күңеленә шик кермәс, хакыйкатьне аңлар, Инша Аллаһ.

***Ләйсән ФӘТХЕТДИНОВА.***

---

# КОРЪӘНИ-КӘРИМНЕҢ МЕТАПРОГРАММАЛЫ ПРОФИЛЕ

***(Ахыры.***
***Башы 1 нче биттә.)***

Кызык, кайсы агым текстларының метапрограммалы профиле Коръәни-Кәримнең метапрограммалы профиле белән туры килер икән? Безне монда нинди дә булса көтелмәгән сюрприз көтәрме?

Әгәр дә әлеге тикшерү методы үз-үзен акласа, дин ягыннан хакыйкать һәм ялганны аеру алымы гына түгел, башка бик күп мөмкинчелекләр дә ачылачак. Мәсәлән, минем гипотеза буенча, ислам эчендәге төрле традицияле барлык текстлар бер үк булмаса да, охшаш метапрограммалы профильләргә ия булырга тиеш. Димәк, без бүгенге көн хезмәтләренең кайсысы хәнәфиләрнең традициясенә туры килгәнлеген, ә кайсылары туры килмәгәнлеген билгели алачакбыз. Киләчәктә ислам дине белеме дөньясының (кешенең эмоциональ дөнья картасына тиң) глобаль картасын төзи һәм ислам диненең күп санлы ислам хәрәкәтләре һәм группалары доктриналарының төрле төсмерләргә бүленүен күзәтә алачакбыз.


Әлеге ачыш киләчәктә бер генә диссертацияне яклауга гына түгел, ә барлык дөнья буенча ислам тикшеренүләренә абсолют рәвештә яңа сулыш кертергә мөмкин.

Гомумән, әлеге мәсьәлә киңрәк тә куела ала. Әгәр дә ислам диненең метапрограммалы профилен башка диннәрнең метапрограммалы профильләре белән чагыштырып карасак, ни булыр? Ахырда нәрсәгә ирешербез: охшашлыккамы, әллә аермалыккамы? Кешелек дөньясының заман башыннан бирле җыелып килгән барлык рухи хәзинәсенең метапрограммалы картасын төзү мөмкин булырмы?

**Рөстәм хәзрәт БАТЫР,**
**Үзәкләшкән дини оешма - ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмәләр шурасы рәисе**
**(islam-portal.ru сайтыннан КФУның V курс студенты Гүзәл Шәмсиева тәрҗемә итте)**

---

## Яңа китап: "Шөкернамә"




"Шөкернамә" китабының яңа гына өченче төзәтелгән басмасы дөнья күрде. Беренче мәртәбә китап өч ел элек басылган иде һәм ул чакта да ул халкыбыз тарафыннан бик яратып каршы алынды. Әлеге хезмәтендә автор күңеленнән чыккан дога-теләкләрне бәян итә. Гөлсем Исхакованың китабы саф татар әдәби телендә булуы белән күпләрдә кызыксыну тудыра.

***Мәгълүмат musulman.su сайтыннан алынды***

# Балаларымның туган телләрен белүен телим

***Кардәшләрем, сезнең киңәшегез кирәк иде! Мин, Иншә Аллаһ, рус милләтендәге кызга өйләнергә ниятлим. Ул өч ай элек ислам динен кабул итте, бүгенге көндә хиҗап киеп йөри, һәрдаим гыйлемгә омтыла.***

***Үземнең балаларымның анасын нәкъ шундый итеп күз алдына китерәм. Минем өчен тормыш иптәшемнең кайсы милләттән булуы беркайчан да мөһим булмады. Шулай да кайчакта балаларымның туган телемне белмәячәкләре турында уйланам. Балаларымның гореф-гадәтләребездән ерак булачаклары борчый. Киңәш бирсәгез иде!..***

**ДИН БЕЛГЕЧЕ ҖАВАБЫ:**

– Рус милләтеннән булган кызга өйләнергә теләвегез куанычлы, чөнки ислам шәригать кануннары буенча яшәүче тормыш иптәше белән яшәп, ул ислам динен дә тиешенчә өйрәнер һәм дин кушканча яшәр. Әгәр ислам динен кабул итүенең сәбәбе сездә генә булса, сезгә Аллаһның мактауларын җиткерәсе килә. Пәйгамбәребез (с.г.в.) дә Муаз бине Җәббалга (аннан Аллаһ разый булсын):

"Синең өчен бер кешене туры юлга бастыру – бар галәм һәм андагы бар әйберләрдән дә файдалырак", – дигән.

Ислам динен кабул итү белән, элеккеге гөнаһлар ярлыкана һәм тормыш өр-яңа чиста биттән башлана дисәк тә була.

Әгәр балаларыгызның туган телегезне, мәдәният һәм гореф-гадәтләрегезне белүләрен телисез икән, аларны тәрбияләүдә үзегез дә актив катнашыгыз. Хәтта балаларыгыз туганчы ук, тормыш иптәшегезне өйрәтсәгез дә яхшы булыр. Тормыш иптәшегез һәм балаларыгыз телне азмы-күпме үзләштергәннән соң, өйдә бары тик туган телдә генә аралашыгыз. Елына бер мәртәбә булса да (күбрәк булса тагы да яхшырак) үзегезнең туган якларыгызга кайтып килегез, шул вакытта балаларыгыз туган телне теоретик яктан гына түгел, практикада да куллана алырлар.

**ПСИХОЛОГ ФИКЕРЕ:**

– Балаларга туган телегезне өйрәтүдән сезне беркем дә тыймый. Әгәр сез тәрбия эшен, тормыш иптәшегезгә генә калдырмыйча, үзегез дә катнашсагыз, балалар телне бик тиз үзләштерәчәк. Сабыйлар олыларга караганда телне тизрәк өйрәнә. Тормыш иптәшегез дә алар белән бергә өйрәнә алачак – тормышта мондый мисаллар шактый очрый.

***Җавап islam.ru сайтыннан алынды***



# Электрон Коръән барлыкка килгән

***Бу Коръәнгә mp3 файллар тупларга, наушниклар һәм flash-карталар да кертеп була.***

Астана кибетләрендә Коръәннең электрон басмасы сатуда пәйда булган. Мондый Коръәнне уку мәҗбүри түгел, аны тыңларга гына да була. Бу яңалык дин тотучыга кирәкле булган сүрәләрне үзе яңгыратачак, казакъ, рус телләрен исәпкә алып, җиде тел арасыннан сайлап алу мөмкинлеге бар.

Изге китапның башка басмалардан аермасы шунда: ул бүләк дизайнерлы һәм аның махсус төргәге бар. Электрон Коръәннең барлык мөмкинлекләре, текст буенча махсус җайланма белән йөрткәннән соң гына ачыла. Бу вакытта китап "җанлана": чын мөәзин тавышы белән ул кирәкле аятьләрне һәм сүрәләрне укый башлый. Комплектка намазны



дөрес уку буенча инструкция генә түгел, ток җыю җайланмасы һәм USB-кабель кергән. Әлеге электрон Коръәнгә mp3 файллар тупларга, наушниклар һәм flash-карталар да кертеп була. Дин әһелләре мондый прогрессны хуплый, дип хәбәр итә tmk.kz (Казахстан татарлары дөньясы) сайты.

# ӘНИЛӘР ХАКЫ

Беркөн бер егет пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) янына килеп:

- Я, Рәсүлуллаһ! Әнием бик картайды. Нәкъ сабый бала кебек булды. Яткан җиреннән тора алмый. Мин аны кулларым белән ашатам, чәй эчерәм. Тәһарәт алдырып, намазлыгы янына күтәреп илтеп куям. Һәр кушканын эшлим, теләгәнен үтим. Я, Рәсүлуллаһ! Әниемнең хакын үти алдыммы? - дип сорады.

Сөекле пәйгамбәребез (с.г.в.):

– Тудырган әниеңнең хакының йөздән бер өлешен дә үти алмадың! - диде.

Егет:

– Ни өчен? Я, Рәсүлуллаһ! Мин әниемнең бер әйткәнен ике тапкыр кабатлатмадым. Үзем шулкадәр хезмәт итәм, һич кенә дә аңа кыенлык китермәдем, – ди.

Рәсүл Әкрам (с.г.в.) әфәндебез:

– Әниең сиңа: "Улым үссен, бөек кеше булсын, озак яшәсен", дип аркасында күтәреп йөртте. Син исә: "Кайчан үләчәк, үлсә котылыр идем", дип хезмәт итәсең. Монда таулар арасындагы кебек аермалык бар. Әниең сиңа баккан саен: "Улым, ни заман үсеп җитәчәксең", дияр иде. Син исә: "Ни заман үләчәк", диясең.




Шулай да бу ниятләрегез арасында булган аермалыкларның даһи бер кыйммәте бар. Син әниеңә никадәр хезмәт итсәң дә, аның хакын үти алмассың. Моны яхшы беләсең. Һичбер бала ата-анасының хакын үти алмас.

Фәкать шуны яхшы белегез ки, син әниеңә болай хезмәт итсәң, Җәнабы Хак сиңа бөек саваплар бирер. Ата һәм ананың ризалыгына лаек булган кеше Җәнабы Хакның ризалыгына да лаек булыр, – дип боера.

***"Дини хикәяләр" китабыннан***

## Төзәтмә

Без газетабызның узган санында (Дин вә мәгыйшәт. – 2011. – №4 (9 сентябрь). – Б. 4.) "Казанда троллейбус пассажирларын "шәһидләр һәм шәһидәләр"дән сак булырга чакыралар" дип исемләнгән мәкалә биргән идек. Бу материалның кайдан алынганлыгын – чыганагын да күрсәттек (kp.ru сайты). Тик ул чакта "Комсомольская правда"ны плагиатлыкка барыр дип башыбызга да китермәдек. Алар ("КП") бу мәкаләне islamrf.ru сайтыннан алып, үзләренең авторын (Максим Милославский) куеп бастырганнар булып чыкты. Ә чынлыкта материалны islamrf.ru хәбәрчесе Нурия Гыйбадуллина эшләгән икән. **Без IslamRF.Ru порталыннан һәм аның корреспондентыннан гафу үтенәбез.**

## Хоккейчы Галимов мөселманча җирләнде

***13 сентябрь көнне Александр Галимовка җеназа намазы укылды. Соңыннан татар хоккейчысы Ярославль шәһәренең Чурилковский зиратының мөселман өлешендә җирләнде.***




"Локомотив" хоккей клубы форварды Александр Галимов самолёт фаҗигасендә алган авыр тән җәрәхәтләре нәтиҗәсендә дүшәмбе көнне якты дөнья белән саубуллашты. Сишәмбе көнне хоккейчы Ярославльдә мөселман гореф-гадәтләре буенча җирләнде.

Иртәнге якта "Арена-2000" боз сараенда хоккейчыны искә алу чарасы узды. Галимов белән хушлашырга аның меңләгән җанатары, дуслары, якыннары һәм туганнары килгән иде, дип яза ria.ru сайты. Ярославль өлкәсе губернаторы Сергей Вахруков һәм "Локомотив" хоккей клубы президенты Юрий Яковлев та хоккейчыны соңгы юлга озатты. "Сашаны барыбыз да ярата идек, ул менә дигән хоккейчы иде. Бәлки, ул Россиянең иң сәләтле уенчыларыннан берсе булгандыр. Аның чиксез мөмкинлекләре, олы киләчәге бар иде. Кызганыч, ул тормышка аша алмады", - диде Юрий Яковлев. Губернатор да "авыр югалту" турында искә алды. Вахруков шулай ук хоккейчының якыннарының барлык ихтыяҗлары кәнәгатьләндереләчәк, дип хәбәр итте.

Исегезгә төшерәбез: бортында "Локомотив" хоккей төркеме уенчылары булган Як-42 самолёты 7 сентябрьдә Ярославль аэропортында фаҗигагә юлыккан иде. 45 кешенең икесе генә исән калды - хоккейчы Александр Галимов һәм инженер Александр Сизов. Табиблар Галимовны саклап калыр өчен 5 көн хезмәт куйды, ләкин, ни кызганыч, тәне 90% янган спортчы дүшәмбе көнне иртән хастаханәдә вафат булды.

**tatartime.com сайтыннан алынды**

## Казанда намаз вакытлары

| Көн | Иртә | Кояш | Зәвәл | Икенде | Ахшам | Ястү | Кыйбла | Көн оз. |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 17.09.2011 | 04:47 | 06:17 | 12:39 | 16:51 | 18:57 | 20:26 | 13:27 | 12:39 |
| 18.09.2011 | 04:50 | 06:19 | 12:38 | 16:49 | 18:54 | 20:23 | 13:27 | 12:34 |
| 19.09.2011 | 04:52 | 06:21 | 12:38 | 16:46 | 18:52 | 20:21 | 13:27 | 12:30 |
| 20.09.2011 | 04:54 | 06:23 | 12:38 | 16:44 | 18:49 | 20:18 | 13:26 | 12:25 |
| 21.09.2011 | 04:56 | 06:25 | 12:37 | 16:42 | 18:46 | 20:15 | 13:26 | 12:21 |
| 22.09.2011 | 04:58 | 06:27 | 12:37 | 16:40 | 18:44 | 20:12 | 13:26 | 12:16 |
| 23.09.2011 | 05:00 | 06:29 | 12:37 | 16:37 | 18:41 | 20:09 | 13:26 | 12:12 |

***Мәгълүмат muslem.ru сайтыннан алынды***

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. №5 (102) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер-верстка:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** Е-505

**Газета бушлай таратыла.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
**Бастыруга кул куелды: 16 сентябрь, 14.00 сәгать.**
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**